# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

## КАРАР

**№195**

**«20» март 2019 ел.**

**Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында » 2014 елның 14 ноябрендәге 218 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 32 нче бүлек, шулай ук «Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» гы 2014 елның 14 ноябрендәге 218 номерлы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 253 номерлы, 2018 елның 7 ноябрендәге 171 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Карарга киләсе эчтәлектәге 2.2 пунктчасын өстәргә:

«2.2. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү:

1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балалары.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра. Салым ташламасы Сәвәләй авыл җирлеге булып торган яшәү урыны буенча теркәү урыны салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасын түләнергә тиешле күләмдә салым түләүчеләргә бирелә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлеге мәгълүмат стендлары һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **С.В.Сабаева**